№3, март, 2018

# Гимназия сулышы

25 нче гимназия укучылары газетасы



## Бүгенге санда


* “Батырлык дәресе”, 1 нче бит.
* “Гимназиядә ”Хәрби парад”, 2нче бит.
* “21 февраль- Халыкара туган тел көне”, 3 нче бит.
* “ Мин паспорт алдым”, 3-бит
* “Без наркотикларга каршы”, 3-4 нче бит.
* “Мин спортны яратам”, 4 нче бит
* Малайлар “ сугышлы” уйный, 4-5 нче бит.
* Язны көткәндә, 6 нчы бит.


## 23 февраль – Ватанны саклаучылар көне.

***Бар бер бәйрәм февральдә***
***Кадерле ул һәркемгә.***
***Аны иң зур бәйрәм дип***
***Мөмкин хәтта әйтергә.***

***Ул – тынычлык бәйрәме,***
***Аны һәр кеше белә-***
***Ватанны саклаучылар***
***Бәйрәме дип йөртелә.***

***Ул-солдатлар бәйрәме.***
***Без котлыйбыз аларны -***
***әтиләрне, абыйларны***
***Һәм бөтен малайларны.***

*******************************************

***Гимназиядә белем алучы малайларны-булачак Ватанны саклаучыларны, ир-ат укытучыларыбызны бәйрәм белән котлыйбыз!***

## Батырлык дәресе

Хәрби – патриотик айлык кысаларында 6 нчы б сыйныфы укучылары катнашында “Батырлык дәресе” үтте. “ Бу сыйныф сәгате Ленинград блокадасын өзү һәм Сталинградта фашист гаскәрләрен тар-мар итүгә 75 ел уңаеннан үтә ,”- дип сүз башлады сыйныф җитәкчесе Светлана Анатольевна. Аида Паненко үз чыгышында 900 көн барган блокада, шырпы кабыннан чак кына зур булган 125 граммлы блокада икмәге, блокада вакытында һәлак булган 1 миллионнан артык кеше күмелгән Пискарево мемориал каберлеге турында сөйләде.

Дәрес гимназия музееның “Хәтер”стенды янында үтте. Биредә гимназиядә эшләүче укытучыларның, хезмәткәрләрнең Бөек Ватан сугышында катнашкан якыннары - туганнарының фоторәсемнәре урын алган.



Менә аларның исемнәре: Гәрәйшин Минхуҗа Гәрәйшинович, Комиссаров Михаил Константинович, Крылов Владимир Александрович, Пикулькин Иван Степанович, Сергеева Таисия Васильевна. “Сугыш еллары һаман ераклаша бара. Без тыныч тормышта яшәсен өчен бабаларыбыз сугыш кырларында һәлак булганнар. Без батырларны онытмабыз”,-дип тәмамлады чыгышын Аида Паненко.

Музей җитәкчесе Егорова С.А. әйтүенчә, әлеге стендка материаллар туплау эше дәвам итә.
Сысоева Екатерина, 6нчы б сыйныфы



## Гимназиядә “Хәрби парад”

14 нче февраль көнне гимназиядә Данлыклы Кораллы Көчләребезнең 100 еллык юбилее уңаеннан һәм Ватан сакчылары көненә багышланган җырлап сафта



йөрү конкурсы уткәрелде. Чарага Бөек Ватан сугышы ветераны З. Д. Дәүләткирев һәм Әфганстан сугышында катнашкан, запастагы офицер П.Б. Данилов та чакырылган иде. “Хәрби парад”ның жюри составында гимназияне тәмамлап, армиядә хезмәт иткән Зарипов Александрның һәм Хөсәенов Айдарның булуы күңелле хәл иде.



Смотрда 11нче сыйныф укучылары беренче урынны, 9нчы А сыйныфы укучылары икенче урынны алды. Сугыш ветераны- ике Кызыл Йолдыз, III дәрәҗә Дан

орденнары кавалеры З. Дәүләткиров әйтүенчә, гимназиядә лаеклы патриотик тәрбия алучы алмаш булуы сөендерә. Хуҗҗәтов Гадел, 7нче г сыйныфы.

## “Халыкара туган тел көне”

Халыкара туган тел көне - һәр милләт, һәр халык өчен бәйрәм көн. Бу көн 2000 нче елдан ЮНЕСКО карары нигезендә билгеләп үтелә башлады.



Бүген дөнья халыклары 6 мең телдә сөйләшә. Безнең гимназиядә 11 милләт вәкилләре белем ала. 20 февральдә үткән “ Туган тел көне”ндә укучылар рус, чуваш, казах, украин телләрендә шигырьләр сөйләделәр, татар телендә җырладылар, милли биюләр башкардылар.



Бу чарадан шул аңлашылды: һәр милләт өчен иң кадерлесе үз ана теле.



Якупова Гүзәл, 9 нчы г сыйныфы

## Мин паспорт алдым

Кеше 14 яшендә беренче паспортын кулга алып илебезнең тулы хокуклы гражданы була. Бу җаваплы вазыйфа икәнен мин паспорт бирү тантанасында аңладым.



Чөнки паспорт - тормыш өчен мөһим документ. Беренчедән, мин җәйге ялда эшкә урнаша алам; икенчедән, 9 сыйныфтан соң теләгән уку йортына укырга керә алам. Тантанада минем әбием һәм бабам да катнашты.

“ Паспортыңны кадерләп сакла, илебезнең чын гражданы бул”,- диде бабам.

Мин Россиянең лаеклы гражданы булырга сүз бирәм! Вихрев Егор, 7 нче б сыйныфы.

## Без наркотикларга каршы



“1 март – халыкара наркоманиягә һәм наркобизнеска каршы көрәш көне” акциясе кысаларында, безнең 25 гимназиядә 7-11 нче сыйныф укучылары белән “Без наркотикларга каршы! ” дип исемләнгән ачык чара үткәрелде.

Кол Гали исемендәге милли китапханәнең баш китапханәчесе Дәүләтшина Әнисә Мокатдисовна наркомания турында бик эчтәлекле китап күргәзмәсе оештырып, безгә анлатма-белешмә бирде, укучыларга наркоманиянең асылы турында бик эчтәлекле һәм оста итеп сөйләде һәм З. Гимаевның “Өмет”, язучы Ф.Бәйрәмованың


“Ахырзаман”, А. Галиеваның “Кайф”,З.Хәкимнең “Наркокурьер” исемле әсәрләреннән өзекләр укыды.

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Осипова Гөлчәчәк Талиповна үзе әзерләгән презентация белән таныштырды, ә Тараканова Вәсилә Кәүсәровна З. Гимаевның “Өмет” исемле хикәясенә буктрейлер һәм тематика буенча электрон китап күргәзмәсе әзерләгән иде.

Ачык чара бик эчтәлекле һәм файдалы булды. Кичә безгә бик ошады.

Кол Гали исемендәге китапханә белән берлектә безнең гимназия даими кулга –кул тотынышып ничә еллар буе эшли, төрле кичәләр үткәрәләр. Без Кол Гали исемендәге китапханә хезмәткәрләренә чиксез рәхмәтебезне белдерәбез.

Сайфуллина Камилә , 11 нче сыйныф



# Малайлар “сугышлы” уйный

Бүген бар дөньяга ап-ак кар яуган. Ул күзләрне камаштыра, керфекләргә күтәрелергә дә бирми. Искиткеч матур күренеш. Әйтерсең лә, кар түгел, ә энҗе-мәрҗәннәр түшәп куйганнар да, алар кояшның гаҗәеп матур нурларында елтыр-елтыр килеп яталар. Шуларга карагач, күңелне чиксез рәхәтлек били.
Әнә, Камил ашыга-ашыга мәктәптән кайтып килә. Ул алдына-артына карамыйча йөгерә генә. Гүя артыннан ач этләр чаба.
Кайтып җитүгә ул тиз генә ашап алды да, тәрәзәдән урамга карады. Җир өстенә яуган ап-ак кар күңелне җилкендереп урамга чакырып тора...
Камил урамга чыкканда анда малайлар бик күп иде инде. Алар башта хоккей уйнадылар. Ошамады. Йөгерешле уены да тиз туйдырды. Шулай ни эшләргә белми йөргәндә, Камилнең башына искиткеч фикер килде: “Әйдәгез, “сугышлы”уйныйбыз,” – диде ул. Аның тәкъдимен малайлар күтәреп алды. Чөнки кыш башланганнан бирле юньләп кар да яуганы юк иде, ә хәзер шундый йомшак ,җепшек кар ява.

Шәп! Малайлар ике командага бүленделәр. Әле теге яктан, әле бу яктан йомарланган карлар оча башлады. Тик алар берсенә дә тими. Димәк “үлмиләр”. Уенчыларга күңелсез булып китте. Шулчак көтмәгәндә, теге яктан атылган кар Камилнең якын дустына эләкте. Бу аның ачуын чыгарды. Хәзер уен кызганнан-кыза бара инде .

“Салкын корал”, ягъни, карлы йомарламнар очып кына тора. Кар-ядрә тиеп, “яраланучылар”артканнан-арта бара. Кайсыныңдыр борыны да канаган хәтта. Бу “кан кою”күпмегә сузылыр иде икән, билгесез. Шулчак, “ сугыш кырына” малайларның әти-әниләре килеп керде.
Көн кичкә авышкан иде. Уен белән мавыгып, малайлар моны сизмәгәннәр дә. Кичке салкын төшкән. Юеш кардан киемнәре чыланып беткән. Өстәвенә борыннан ага. Иң ачуны китергәне янәшәдән сине тирги-тирги әти-әниләр атлый. Ә син борылып карыйсың да, көндәшеңә астан гына йодрык яныйсың. Ул да, сиңа усал караш ташлап, телен күрсәтә. Их, юньсез күрмәгәнеңне күрсәтермен әле мин сиңа, янәсе. Өйгә кайткач ,Камил бүлмәсенә кереп эшләнеп бетмәгән өй

эшен эшли башлады. Уенның үз вакыты, ә өй эшен эшләмәсәң “икеле”аласыңны яхшы беләсең.
Икенче көнне мәктәптән кайтканда , Камил үзләренең урамда яшәүче малайларны очратты. Алар кичәге хәлне көлешә – көлешә сөйләп, дуслашып, өйләренә таба киттеләр.
Фәйзулин Әмир,7 в сыйныфы

## Мин спортны яратам

Гимназиядә укучы малайлар нинди спорт төрләре белән шөгыльләнә икән? Сорауга җавап табу өчен мин 6нчы В сыйныфы укучысы Фәйзуллин Айнурга мөрәҗәгать иттем.

- Айнур, син спортның нинди төрен яратасың?

- Мин Корея халкының кул сугышы төрен яратам һәм тхэквондо белән шөгыльләнәм.

–Тхэквондо нәрсәне аңлата?



Корея теленнән ул “куллар һәм аяклар ярдәмендә каршы тору”дип тәрҗемә ителә.

- Айнур, син әлеге спорт төре белән ничә ел шөгыльләнәсең , аның файдасы бармы?


- Мин 4 ел дәвамында тхэквондо белән шөгыльләнәм. Бу спорт түземле булырга, үз-үзеңне контрольдә тотарга , гадел һәм намуслы булырга өйрәтә. Әлбәттә, өйрәнгән ысулларны бары яхшы максатларда кулланачакмын.

– Айнур, уңышларың турында сөйлә әле?

Тхэквондода билбау системасы әзерлек дәрәҗәсен белдерә. Минем билбау зәңгәр төстә. Бу спорт разрядлары буенча бишенче ГЫП дигәнне аңлата. Күп кенә ярышларда катнашып медальләр алдым. Әле ике атна элек Ижевск шәһәрендә Калашников М. Т. исемендәге турнирда катнаштым. 12-13 яшьлек үсмерләр арасында, 37 кг үлчәү авырлыгында ярышып, II урын алдым.

-Рәхмәт ,сиңа, Айнур. Спортта һәм укуда уңышлар юлдаш булсын сиңа !

Гыйльманова Алия, 6нчы А сыйныфы.



## Язны көткәндә

**Хөрмәтле укучыларыбыз! Үзегезне ихлас күңелдән ямьле яз белән котлыйбыз! Яз тормышыбызга яңа көч, омтылыш, ышаныч алып килсен.**



Яз март аеннан башлана. Көннәр озыная, төннәр кыскара башлый, беренче яңгырлар ява. Көндез күктә кояш елмая, җирне җылыта. Урамда саф, җылы һава, кар эри, гөрләвекләр ага. Елгаларда һәм күлләрдә бозлар эри. Җылы яктан кучмә кошлар очып кайталар.Урманнарда хайваннар уяна, алар кышкы туннарын салалар. Апрельдә беренче язгы чәчәкләр күренә башлый.

Агачлар, куаклар яфрак яра. Шәһәр парклары ямьләнә.   Менә шуңа яз айларын бик яратам мин. Хафизова Әдилә, 5 нче г сыйныфы

***

Агачлар әле шәрә,
Утыралар боегып.
Салкынча җилләр искәндә,
Ак шәлләрен ябынып.
Кар ята тирә-якларда,
Тиздән язлары җитәр,
Кояш нурларын сибүгә,
Гөрләвекләр дә китәр.
Кошлар кайтыр җылы яктан,
Сагынып туган ягын.
Өй кыекларына кунып,
Сузып сайрарлар  тагын.
Ләйсән Сәгыйрова



**Редактор: Хуҗҗәтов Г.**
**Проект җитәкчесе: Шарапова Н.Н.**

### Ә сез беләсезме?

Кеше организмына витаминнар кирәк. (“Вита” латинчадан – тормыш дигән сүз.) Бигрәк тә яз көне,  чөнки озак кыштан соң организм талчыга. Витаминнар аз булганда кеше авырый.  Хәзер 30 га якын витамин билгеле. А витамины үсү өчен кирәк. Ул күзнең яхшы күрүенә булыша. В витаминнары нерв системасын ныгыта, баш мие эшчәнлеге өчен кирәк. С витамины тешләр өчен кирәк, бу витамин җитмәсә, кеше зәңгелә (цинга) белән авырый. Д витамины сөяк ясалуга булыша. Витаминнар яшелчәдә, җиләк-җимештә бик күп. А витамины кишердә күп. В витаминына борчак, Пекин кәбестәсе бай.  Ә С витамины суганда, кәбестәдә, бәрәңгедә, лимонда,  әфлисунда күп. Д витамины кояш нурлары ярдәмендә барлыкка килә. Википедия сайтыннанн.